**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 02 » 06 2020 № 344

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының 2015 ел, 23 март, 96 нче номерлы
карары белән расланган, муниципаль учреждениесе җитәкчесе
вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждениесе
җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти
характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ
булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти
характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакындагы
нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясына, Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 23.06.2014 ел, №460 Указына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы бурычлар хакында мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәне раслаү хакында" 28.02.2013 ел, №137 карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының 23.03.2015 елның 96 нче номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматләр бирү хакындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

карар исеме һәм тексты буенча “чыгымнар” сүзен төшереп калдырырга;

карар белән расланган Нигезләмәнең исемендә һәм тексты буенча "чыгымнар"

сүзне төшереп калдырырга.

4 пунктта:

«Ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда ел саен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш: http://aksubayevo.tatarstan.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов